Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Кәләй авыл Советы

КАРАРЫ

12 декабрь 2024 ел №109

Әлмәт муниципаль районы Кәләй авыл Советының 2018 елның “24” августындагы 93 номерлы «Әлмәт муниципаль районы Кәләй авыл җирлегенең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 25 сентябрендәге 829 номерлы «Татарстан Республикасында депутатларның, даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларның, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» карары нигезендә

Кәләй авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Кәләй авыл Советының 2018 елның “24” августындагы 93 номерлы «Әлмәт муниципаль районы Кәләй авыл җирлегенең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кәләй авыл Советының 2018 елның “05” декаберендәге 107 номерлы, 2020 елның “11” декаберендәге 12 номерлы, 2022 елның “27” октяберендәге 57 номерлы, 2022 елның “14” декаберендәге 62 номерлы, 2024 елның “26” июнендәге 101 карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарга 1 нче кушымтадагы таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлмәт муниципаль районы Кәләй авыл җирлегенең муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәре

| Вазыйфаның исеме | Вазыйфаи оклад (11 группа хезмәткә түләү) |
|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | 20 985 |

| | |
|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесенең урынбасары | 20 566» |

1.2. карарга 2 нче кушымтадагы таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлмәт муниципаль районы Кәләй авыл җирлегенең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайлаулы вазыйфаи затларының ай саен акчалата бүләкләү күләмнәре

| Вазыйфаның исеме | Ай саен акчалата бүләкләү күләме (11 группа хезмәткә түләү) |
|---|---|
| Башлык | 20 991 |
| Башлык урынбасары | 15 085» |

2. Әлеге карарны Кәләй авылы, Специалистлар урамы, 2Д йорт, Сабанче авылы, Яббаров урамы, 1 йорт торак пункт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, шулай ук Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 январеннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Кәләй авыл
җирлеге башлыгы С.П. Бастылева